| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г. Казань № 661-90/тэ-2023

Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2021 №520-110/тэ-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2024 ел өчен үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 14.12.2023 №58-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2024 елга җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмалары сатып ала торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында һәм 2024 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе югалтуларны компенсацияләү максаты белән

җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2022-2024 елларга тарифлар билгеләү турында» 14.12.2021 №520-110/тэ-2021 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2022 №561-124/тэ-2022 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), аны яңа редакциядә биреп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2021 №520-110/тэ-2021 карарына
кушымта (Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 661-90/тэ-2023
карары редакциясендә)

Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» АҖ тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2022-2024 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләштерүче пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставка-лы, сум/Гкал | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 809,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 838,38 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 899,60 <*> | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 899,60 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 1 027,19 | - | - | - | - | - |

<*> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2022 №561-124/тэ-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге